ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2019 елның 2 нче августы** **Чистай шәһәре** **№ 405**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында”гы 2019 елның 28 июнендәге 336 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Авыл хуҗалыгын үстерү турында”гы 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон таянып, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында”гы 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексына нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында»гы 2019 елның 28 июнендәге 336 номерлы карары белән расланган 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү программасына үзгәрешләр кертергә, шул исәптән түбәндәге эчтәлекле 4.2 пунктны өстәргә:

«Комиссия тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларда мөгезле эре терлек асраугa матди ярдәм күрсәтү турында Карар кабул ителгән очракта, саву аппаратлары Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гражданнарга кабул итү-тапшыру акты буенча бушлай тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов